**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 24 февраль | № 108

г. Казань

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында

Балалар сәламәтлеген саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\108.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 24 февраль, 108 нче
карары белән расланды

## Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты

### 1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар категорияләре

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) файдаланучылар – Татарстан Республикасында даими яши торган ясалма һәм катнаш туклануч‍ы, медицина оешмасында (яшәү урыны буенча) амбулатория исәбендә торучы өч яшькә кадәрге түбәндәге балалар:

җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән халыкның  яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдән булган. Гаиләдә әлеге яшьтәге ике яки аннан да күбрәк бала булса, мондый хокукка һәр бала ия була;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар тукλануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын  финанслау  тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын  финанслау  тәртибенә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән авыруы булган. Гаиләдә әлеге яшьтәге ике яки аннан да күбрәк бала булса, мондый хокукка һәр бала ия була.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану хокукы бу бүлектә билгеләнгән берничә нигез буенча булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү бу нигезләрнең берсе буенча гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыны тулы кыйммәтле туклану белән бушлай тәэмин итү хокукына ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсе ия була.

### 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең хокукый нигезләре

Дәүләт хезмәте түбәндәге закон актлары, норматив хокукый актлар һәм башка актлар, документлар нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы;

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 ел, 30 март, ФЗ-52 нче Федераль закон;

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 ел, 2 май, ФЗ-59 нчы Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 ел, 22 июль, ФЗ-123 нче Федераль закон;

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 ел, 21 ноябрь, ФЗ-323 нче Федераль закон;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга карата санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.1.3.2630-10 нормаларын раслау турында» 2010 ел, 18 май, 58 нче карары;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Дару препаратларын, медицина билгеләнешендәге әйберләр һәм дәвалану туклануы өчен махсус продуктлар билгеләү һәм язып бирү тәртибе турында» 2007 ел, 12 февраль, 110 нчы боерыгы;

тиешле елга һәм план чорына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 ел, 22 декабрь, ТРЗ-87 нче Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын хисаплау тәртибе турында» 2009 ел, 24 декабрь, 882 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт

продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

медицина оешмаларын гамәлгә кую документлары;

медицина оешмаларының локаль актлары;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча башка актлар.

## 3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| Т/с | Документлар исемлеге | Документ бирүне тәэмин итүче оешма | Документ бирелгән көннән аның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артып китмәүне раслый торган белешмә кәгазе<br>(бала турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары нигезендә Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы төзи торган җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү | «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдәге балаларның төбәк регистрында булмаган очракта) | | |
| 2. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары һәм законнар нигезендә бирелә торган туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алу өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Дару препаратлары, медицина билгеләнешендәге әйберләр һәм дәвалану туклануы өчен махсус продуктлар билгеләү һәм язып бирү тәртибе турында» 2007 ел, 12 февраль, 110 нчы боерыгы белән расланган 148-1/у/06 (л) формасы буенча рецепт (алга таба – рецепт) | Амбулатория медицина ярдәме күрсәтүче һәм законнар нигезендә рецептлар бирүне тәэмин итүче медицина оешмасы (алга таба – медицина оешмасы) | 1 ай |
| 3. | Гражданнарның мәҗбүри медицина иминияте полисы | иминият медицина оешмасы | законнар нигезендә |
| 4. | Бала туу турында таныклык | граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнары | законнар нигезендә |

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибенә һәм шартларына карата таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – Учреждение) тарафыннан күрсәтелә.

4.2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ай саен, 20 сеннән дә соңга калмыйча, керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балаларның төбәк регистры сегментын Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына тапшыра.

Төбәк регистры сегментын тапшыру, керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балаларның төбәк регистры сегменты мәгълүматларын кабул итү-тапшыру актына кул куеп, якланган ысул белән DBF-файл рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы ай саен,

15 еннән дә соңга калмыйча, керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче һәм социаль ярдәм чарасын күрсәтү кысаларында түләүсез тулы кыйммәтле туклану алган өч яшькә кадәрге балалар турында Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүматлар тапшыра.

Керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче һәм социаль ярдәм чарасы күрсәтү кысаларында түләүсез тулы кыйммәтле туклану алган өч яшькә кадәрге балалар турында мәгълүмат бирү, түләүсез тулы кыйммәтле туклану алган өч яшькә кадәрге балалар турындагы мәгълүматларны кабул итү-тапшыру актына кул куеп, яклanган ысул белән DBF-файл рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Медицина оешмалары ай саен, агымдагы айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән авыруы булган өч яшькә кадәрге балалар турындагы мәгълүмат белән төбәк регистры сегментын тапшыра.

4.5. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары нигезендә агымдагы айның 25 еннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекләр һәм хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар категорияләре яктылыгында табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучыларның җыелма төбәк регистрын (алга таба – җыелма регистр) төзи һәм аны ай саен яңартып тора.

4.6. Медицина оешмасының участок педиатры, әгәр дә җыелма регистрда бала турында мәгълүмат яки гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артмауны раслый торган «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлегенең белешмә кәгазе, гражданнарның мәҗбүри медицина иминияте полисы, бала туу турындагы таныклык булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән каралган таләпләр нигезендә рецепт бирә. Рецепт 1 айга бирелә. Медицина оешмасы участок педиатрының җыелма регистрга керү мөмкинлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны

табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары нигезендә якланган мәгълүмат элемтә каналы буенча гамәлгә ашырыла.

4.7. Рецепт дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучының атасына яки анасына (законлы вәкиленә) бирелә.

Рецептта баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, рецепт язып бирелгән көнгә яше, йорт адресы, туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары алу күрсәткечләре (авыруның диагнозын күрсәтеп, социаль яки медицина күрсәткечләре), туклану өчен сөт продуктының исеме һәм аның көнлек күләме, рецептның гамәлдә булу вакыты күрсәтелә.

Туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын җибәрү медицина оешмалары каршындагы сөт ризыкларын бирү пунктларында (сөт кухняларында, сөт өләшү пунктларында) гамәлгә ашырыла. Туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын кайтарту графиклары, эш режимы сөт ризыклары бирү пунктларында урнаштырыла.

4.8. Медицина оешмалары:

агымдагы елның 1 гыйнварыннан башлап, һәр биш календарь көндә табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучылар саны турында җыелма гариза төзи һәм Учреждениегә җибәрә;

туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын үзәк өләшү пунктларына китергән вакыттан 48 сәгать эчендә аларны законнар нигезендә баланың яшенә карап расланган күләмнәр нормативлары буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларга таратуны тәэмин итә.

4.9. Учреждение:

агымдагы елның 1 гыйнварыннан башлап, һәр биш календарь көндә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре яктылыгында продукция күләмнәре буенча җыелма гариза төзи һәм законнар нигезендә һәм Учреждение сайлап алган туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары җитештерүчегә җибәрә;

туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын китертүне, шул исәптән китертү вакытын, һәр төр яктылыгында продукция санын көн саен мониторинглауны гамәлгә ашыра.

4.10. Туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары җитештерүче, агымдагы елның 1 гыйнварыннан башлап, һәр биш календарь көндә туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын аларны кайтарту турындагы шартнамәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә китерүне тәэмин итә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең матди-техник тәэмин ителешенә карата таләпләр

5.1. Учреждение дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларга территория буенча якын бинада урнаша.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бина законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килә.

5.3. Бина үзәкләштерелгән җылыту системасы белән җиһазландырыла.

5.4. Бина телефон элемтәсе белән тәэмин ителә.

5.5. Бина янгын һәм сак сигнализациясе системалары белән җиһазландырыла.

5.6. Янәшәсендәге территория киртә белән тотып алына, төзекләндерелә һәм яшелләндерелә.

5.7. Җиһазлар, инвентарь билгеләнгән санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормаларына туры килә.

5.8. Учреждение дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру җиһазлары белән җиһазландырыла.

## 6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең куркынычсызлыгына карата таләпләр

6.1. Учреждение законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлә.

6.2. Учреждение бүлмәләре «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 ел, 22 июль, ФЗ-123 нче Федераль закон белән билгеләнгән янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә һәм федераль законнарда билгеләнә торган санитария-эпидемиология нормаларына туры килә.

6.3. Җиһазлар, приборлар, аппаратура эксплуатацияләү документлары нигезендә катгый билгеләнештә файдаланыла, техник яктан төзек хәлдә тотыла.

6.4. Учреждение күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм иминлеге өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

## 7. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдаланучылар өчен кулай булуын тәэмин итә торган таләпләр

7.1. Учреждение Татарстан Республикасы территориясендә урнаша.

7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү, Учреждениенең эш режимын исәпкә алып, ел әйләнәсендә гамәлгә ашырыла.

7.3. Учреждениенең эш режимы эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән регламентлаштырыла.

## 8. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең кадрлар белән тәэмин ителеше дәрәҗәсенә карата таләпләр

8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү өчен Учреждение тарафыннан куела торган таләпләр буенча кирәкле профильле белеме һәм һөнәри әзерлеге булган белгечләр (алга таба – белгечләр) Учреждениегә эшкә кабул ителә.

8.2. Белгечләр законнарда билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнә һәм үз квалификацияләрен күтәрә.

8.3. Белгечләр, аларның бурычларын, хокукларын һәм җаваплылыгын билгели торган вазыйфаи тәгълимнамәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша.

8.4. Белгечләр уставны, эчке хезмәт кагыйдәләрен үтәргә, вазыйфаи тәгълимнамәләр нигезендә функциональ вазыйфаларын сыйфатлы итеп башкарырга, һөнәри этика буенча катгый эш итәргә тиеш.

## 9. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны алар аннан файдалану турында мөрәҗәгать иткәндә һәм аларга дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мәгълүмат белән тәэмин итүгә карата таләпләр

9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат (алга таба – мәгълүмат) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы таләпләре нигезендә урнаштырыла.

9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар өчен мәгълүматны Учреждение гражданнар игътибарына массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру, Учреждениенең мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша www.minzdrav.tatarstan.ru, www.dcmz.tatarstan.ru сайтларында урнаштырып җиткерә.

9.3. Учреждениенең гражданнар игътибарына мәгълүмат җиткерү ысулы, вакытлары һәм тәртибе законнар нигезендә билгеләнә.

## 10. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Стандартның 3 бүлегендә күрсәтелгән документларның булмавы нигез булып тора.

## 11. **Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре тасвирламасы**

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе түбәндәге индикаторлар белән тасвирлана:

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хисаплау формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик мәгънәсе | Авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | % | Жо х 100% / Ж, монда:<br>Жо – дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның хисап чорында кергән нигезле шикаятьләре саны;<br>Ж – дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның хисап чорында кергән шикаятьләре гомуми саны | дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар шикаятьләрен һәм алар буенча күрелгән чаралар турындагы мәгълүматларны анализлау нигезендә билгеләнә | 0 | 9 |

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хисаплау формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик мәгънәсе | Авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| Штаттагы хезмәткәрләр белән комплектлану | % | $Ч_ф$ / $Ч_{шр}$×100,<br>монда:<br>$Ч_ф$ – Учреждение хезмәткәрләренең факттагы саны;<br>$Ч_{шр}$ – Учреждение хезмәткәрләренең штат расписаниесе белән күздә тотылган саны | мониторинг нәтиҗәләре | 100 | 8 |
| Хезмәтне вакытын бозып күрсәтү очраклары саны | берәмлек | Нс – үзәк өләшү пунктына сөт продуктларын һәм катнашмаларын кайтарту вакытын бозу очраклары саны | мониторинг нәтиҗәләре | 0 | 6 |

## 12. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын үтәмәгән өчен шикаятьләр бирү, теркәү һәм аларны тикшерү тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) Учреждениегә язма рәвештә кәгазь чыганакта йә электрон рәвештә бирелә. Учреждение җитәкчесе кабул иткән карарларга карата шикаятьләр югарыдагы органга (ул булган очракта) бирелә йә, ул булмаса, Учреждение җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры карала.

12.2. Шикаять почта буенча, купфункцияле үзәк, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Учреждениенең рәсми сайты, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча бердәм портал» федераль дәүләт мәгълүмат системасы йә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча төбәк порталы буенча җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять теркәлгән көненнән унбиш эш көне эчендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан, ә Учреждениенең, Учреждение вазыйфаи затының гариза бирүчедән документлар кабул итүдән һәм җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Учреждение дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре хакында язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә нигезле җавап җибәрә.

12.6. Граждан (аның законлы вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле булган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

## 13. Дәүләт хезмәте күрсәтүне дәүләт хакимияте органнары тарафыннан тикшерүдә тоту тәртибе

13.1. Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәүне тикшерүдә тоту Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм законнарда күздә тотылган очракларда башка органнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 14. Дәүләт хезмәтен түләүле яки түләүсез күрсәтү турында мәгълүмат

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларга дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

---